КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 9 октябрь г.Казань № 1273

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, Татарстан Республикасының дәүләт бюджеттан тыш фондлары белән идарә итү органнары һәм аларның территориаль органнары, ведомстволарындагы казна учреждениеләре функцияләрен тәэмин итүгә норматив чыгымнарны билгеләү кагыйдәләрен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы ихтыяҗларын тәэмин итү өчен сатып алулар өлкәсендә нормалаштыру турында хокукый актлар эшләү һәм кабул итү тәртибенә, әлеге актларны карап тотуга һәм аларның үтәлешен тәэмин итүгә таләпләрне раслау хакында» 2016 ел, 20 апрель, 242 нче карарына үзгәрешләр кертү турында» 2017 ел, 28 июнь, 442 нче карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, Татарстан Республикасының дәүләт бюджеттан тыш фондлары белән идарә итү органнары һәм аларның территориаль органнары, ведомстволарындагы казна учреждениеләре функцияләрен тәэмин итүгә норматив чыгымнарны билгеләү кагыйдәләрен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы ихтыяҗларын тәэмин итү өчен сатып алулар өлкәсендә нормалаштыру турында хокукый актлар эшләү һәм кабул итү тәртибенә, әлеге актларны карап тотуга һәм аларның үтәлешен тәэмин итүгә

таләпләрне раслау хакында» 2016 ел, 20 апрель, 242 нче карарына үзгәрешләр кертү турында» 2017 ел, 28 июнь, 442 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

преамбулада «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт органнары, дәүләт бюджеттан тыш фондлар белән идарә итү органнары һәм муниципаль органнар функцияләрен, тиешле территориаль органнар һәм ведомстводагы казна учреждениеләрен дә кертеп, тәэмин итүгә норматив чыгымнарны билгеләүнең гомуми кагыйдәләре турында» 2014 ел, 13 октябрь, 1047 нче карары» сүзләрен «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт органнары, бюджеттан тыш дәүләт фондлары белән идарә итү органнары һәм муниципаль органнар, Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезендә аеруча әһәмиятле дип билгеләнгән фән, мәгариф, мәдәният һәм сәламәтлек саклау учреждениеләре (шул ук эзлеклелектә территориаль органнарны һәм ведомство буйсынуындагы казна учреждениеләрен кертеп), шулай ук «Росатом» атом энергиясе буенча дәүләт корпорациясе, «Роскосмос» космос эшчәнлеге буенча дәүләт корпорациясе функцияләрен тәэмин итүгә норматив чыгымнарны билгеләүнең гомуми кагыйдәләре турында» 2014 ел, 13 октябрь, 1047 нче» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, Татарстан Республикасының дәүләт бюджеттан тыш фондлары белән идарә итү органнары һәм аларның территориаль органнары, ведомстволарындагы казна учреждениеләре  функцияләрен тәэмин итүгә норматив чыгымнарны билгеләү кагыйдәләрендә (алга таба – Кагыйдәләр):

8 пунктта «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының дәүләт учреждениеләре тарафыннан дәүләт эшләрен башкаруга чыгымнар нормативларын хисаплап чыгару тәртибен һәм дәүләт эшләрен башкаручы Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләренең норматив санын хисаплап чыгару методикасын раслау турында» 2013 ел, 1 июнь, 376 нчы карары» сүзләрен «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының дәүләт учреждениеләре тарафыннан дәүләт эшләрен башкаруга (хезмәтләрен күрсәтүгә) чыгымнар нормативларын хисаплап чыгару тәртибен һәм дәүләт эшләрен башкаручы Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләренең норматив санын хисаплап чыгару методикасын раслау турында» 2013 ел, 1 июнь, 376 нчы карары» карары сүзләренә алмаштырырга;

9 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9. Автомобиль транспортын тотуга норматив чыгымнар ел саен, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына, аларның территориаль органнарына һәм ведомство буйсынуындагы учреждениеләренә хезмәт күрсәтә торган транспорт чараларының норматив саны, үткән юлы һәм аларны агымдагы карап тоту чыгымнары турында» 2018 ел, 1 декабрь, 1073 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына, аларның территориаль органнарына һәм ведомство буйсынуындагы учреждениеләренә хезмәт күрсәтә торган транспорт чараларын агымдагы карап тотуга норматив еллык чыгымнарны хисаплап чыгару тәртибенә һәм Хезмәт максатларында шәхси транспорттан файдаланган өчен компенсация турындагы нигезләмәләргә таянып, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән раслана.»;

Тәртипнең кушымтасында:

6 пунктның алтынчы абзацында «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә алмаштырырга;

66 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«66. Транспорт чаралары хуҗаларының гражданлык җаваплылыгын мәҗбүри иминләштерү полисларын сатып алуга норматив чыгымнар (әгәр автомобильләрне тоту чыгымнары нормативларында каралмаган булса) Россия Федерациясе Үзәк банкының «Транспорт чаралары хуҗаларының гражданлык җаваплылыгын мәҗбүри иминләштерү буенча иминият тарифлары турында» 2021 елның 8 декабрендәге 6007-У номерлы күрсәтмәсендә билгеләнгән иминият тарифларының база ставкалары һәм иминият тарифлары коэффициентлары нигезендә билгеләнә.»;

76 пунктның сигезенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләрен һөнәри үстерү чараларына дәүләт заказы турында» 2020 елның 24 апрелендәге ПУ-252 номерлы Указы нигезендә Татарстан Республикасы дәүләт органының дәүләт хезмәте һәм кадрлар мәсьәләләре бүлекчәсе ел саен «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәтнең кадрлар составы бердәм мәгълүмат системасы» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасында Татарстан Республикасы дәүләт органының чираттагы елга граждан хезмәткәрләрен һөнәри үстерү чараларын гамәлгә ашыру турындагы гаризасын булдыра. Заявка Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләрнең һөнәри үстерү чараларына дәүләт заказын формалаштыру тәртибе турында» 2010 ел, 25 июнь, 519 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләрен һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләрне һөнәри үстерү чараларын гамәлгә ашыру буенча һәм укуга җибәрелә торган әлеге хезмәткәрләрнең фаразлана торган саны буенча, Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары төркемнәре һәм категорияләре, өстәмә һөнәри белем алу төрләре, формалары һәм сроклары буенча хезмәт күрсәтүләрнең минималь бәясенең икътисадый нормативлары нигезендә формалаштырыла.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин